**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет**

**Старосалмановского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Иске Салман авыл җирлеге**

**Советы**

422894, РТ, Алькеевский район, с. Старые Салманы, Клубная, 1
тел: : 8 (84346) 79-8-49

Адресы: 422894, РТ, Әлки районы, Иске Салман авылы, Клуб ур., 1
факс: 8 (84346) 79-8-49

**РЕШЕНИЕ** Иске Салман авылы **КАРАР**

2022 елның 21 июне 52 №

Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 01 апрелендәге “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 90-ФЗ номерлы Федераль закон, "Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябре 20 номерлы карар белән расланган "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

7 пунктның «в» пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) үз чыгымнары, шулай ук һәр алыш - биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, шулай ук һәр алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балалары тарафыннан белешмәләр тапшыру елыннан (алга таба-хисап чорында) календарь ел дәвамында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) - алыш-биреш ясалган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр»;